**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
АЙБАШ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
422726, Татарстан Республикасы, Биектау районы,
Айбаш авылы, Үзәк ур., 1А

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЙБАШСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422726, Республика Татарстан, Высокогорский район,
с. Айбаш, ул. Центральная, 1А

тел./факс 8(84365) 60-7-23, e-mail: Ayb.Vsg@tatar.ru

---

**КАРАР** **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

**2 декабрь 2022 ел** **№ 6**

**Биектау муниципаль районы Айбаш авыл җирлеге башкарма комитетының 11.11.2019 № 11 номерлы «Бердәм тариф челтәре кагылмый торган баш бухгалтерлар һәм бухгалтерлар, бюджет өлкәсенең аерым оешмалары хезмәткәрләренең, Биектау муниципаль районы Айбаш авыл җирлеге башкарма комитетының хәрби-исәпкә алу хезмәткәрләренең хезмәт хакын оештыру һәм түләү шартлары турында" карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Оборона министрының "Россия Федерациясе хәрби частьләре һәм Кораллы Көчләре оешмаларының граждан персоналына хезмәт хакы күләмнәрен арттыру турында" 2022 елның 30 сентябрендәге 587 номерлы боерыгы нигезендә һәм муниципаль берәмлек учреждениеләре хезмәткәрләренә хезмәт хакы түләү системасын камилләштерү максатларында Биектау муниципаль районы Айбаш авыл җирлеге башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1.2022 елның 1 октябреннән «Айбаш авыл җирлеге Башкарма комитетының Бердәм тариф челтәре кагылмаган аерым бюджет оешмалары хезмәткәрләренең, баш бухгалтерлары һәм бухгалтерлары, хезмәт өчен түләү шартлары турында» Башкарма комитетның 11.11.2019 ел, №11 карары (26.12.2019 № 14, 30.09.2020 № 6, 26.10.2020 № 7, 02.12.2022 № 5 карарлары редакциясендә) белән расланган хәрби-исәпкә алу хезмәткәрләренең хезмәт окладлары күләмен 1,04 тапкыр арттырырга.

2.Биектау муниципаль районы Айбаш авыл җирлегенең хәрби-хисап хезмәткәрләренә (муниципаль хезмәткәрләр вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан тыш) хезмәт хакы түләү турындагы Положениенең 2 нче кушымтасының 2 нче абзацында «6552» санын «6815» санына алыштырырга.

3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының рәсми сайтында: http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ веб-адрес буенча һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы»нда: http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырып бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

4. Бу карар рәсми басылып чыккан (халыкка игълан ителгән) көннән үз көченә

керә һәм 2022 елның 1 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Айбаш авыл җирлеге
Башкарма комитет җитәкчесе Р.Р. Сафиуллин